РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 19 » 05 2021 г. № 389

2021 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы буенча авыл территорияләрендә торак урынны наем шартнамәсе буенча торак төзүгә финанс ярдәме күрсәтүгә чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә бирелә торган субсидия күләмен исәпләү өчен гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019елның 31 маендагы 696 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында» 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы карары, «Татарстан Республикасы авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга муниципаль районнарның торак наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзелеше буенча чыгымнары йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасы авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясен раслау хакында» карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 14 августындагы 599 номерлы “2020-2025 елларга ТР ЮМР авыл территорияләрен комплекслы үстерү” муниципаль программасын раслау турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Торак урынын наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә 2021 елга субсидияләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен 42,400,0 сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә өч эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Н.А. Әбилтарова
2-76-81